# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О регулировании отдельных вопросов в сфере социального обслуживания граждан в Республике Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 ноября 2014 года

### Глава 1. **Общие положения**

#### Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон регулирует отдельные вопросы в сфере социального обслуживания граждан в Республике Татарстан (далее – сфера социального обслуживания).

#### Статья 2. **Правовое регулирование отношений в сфере социального обслуживания**

1. Отношения в сфере социального обслуживания регулируются Федеральным законом от 28 декабря 2013 года № 442-ФЗ «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации» (далее – Федеральный закон «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации»), принимаемыми в соответствии с ним другими федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом, другими законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

2. Основные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, в каком они определены в Федеральном законе «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации».

МИНЮСТ РТ
Входящий № 24736
19 ДЕК 2014
от « » 20 г.

## Глава 2. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания**

### Статья 3. **Полномочия Государственного Совета Республики Татарстан в сфере социального обслуживания**

К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в сфере социального обслуживания относятся:

1) законодательное регулирование отношений в сфере социального обслуживания;

2) осуществление контроля за соблюдением и исполнением законов Республики Татарстан в сфере социального обслуживания;

3) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан.

### Статья 4. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере социального обслуживания**

К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере социального обслуживания относятся:

1) определение органа государственной власти Республики Татарстан, уполномоченного на осуществление предусмотренных Федеральным законом «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации» и настоящим Законом полномочий в сфере социального обслуживания (далее – уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания);

2) утверждение, финансовое обеспечение государственных программ Республики Татарстан в сфере социального обслуживания;

3) установление порядка реализации программ в сфере социального обслуживания, в том числе инвестиционных программ;

4) утверждение регламента межведомственного взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан в связи с реализацией полномочий Республики Татарстан в сфере социального обслуживания;

5) утверждение порядка организации осуществления республиканского государственного контроля (надзора) в сфере социального обслуживания;

6) утверждение нормативов штатной численности организаций социального обслуживания, находящихся в ведении Республики Татарстан (далее – организации социального обслуживания Республики Татарстан), нормативов обеспечения мягким инвентарем и площадью жилых помещений при предоставлении социальных услуг указанными организациями;

7) утверждение норм питания в организациях социального обслуживания Республики Татарстан;

8) утверждение порядка предоставления социальных услуг поставщиками социальных услуг;

9) установление порядка утверждения тарифов на социальные услуги на основании подушевых нормативов финансирования социальных услуг в Республике Татарстан;

10) утверждение размера платы за предоставление социальных услуг и порядка ее взимания;

11) утверждение порядка межведомственного взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан при предоставлении социальных услуг и социального сопровождения;

12) утверждение порядка формирования и ведения реестра поставщиков социальных услуг и регистра получателей социальных услуг;

13) организация поддержки социально ориентированных некоммерческих организаций, благотворителей и добровольцев, осуществляющих деятельность в сфере социального обслуживания в Республике Татарстан в соответствии с федеральными законами и законами Республики Татарстан;

14) установление мер социальной поддержки и стимулирования работников организаций социального обслуживания Республики Татарстан;

15) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 5. **Полномочия уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания**

1. Государственное управление в сфере социального обслуживания в Республике Татарстан осуществляет уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания.

2. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания в пределах своих полномочий осуществляет:

1) разработку государственных программ Республики Татарстан в сфере социального обслуживания;

2) республиканский государственный контроль (надзор) в сфере социального обслуживания;

3) функции и полномочия учредителя организаций социального обслуживания Республики Татарстан;

4) координацию деятельности поставщиков социальных услуг, общественных организаций и иных организаций, осуществляющих деятельность в сфере социального обслуживания в Республике Татарстан;

5) формирование и ведение реестра поставщиков социальных услуг и регистра получателей социальных услуг;

6) обеспечение бесплатного доступа к информации о поставщиках социальных услуг, предоставляемых ими социальных услугах, видах социальных услуг, сроках, порядке и об условиях их предоставления, о тарифах на эти услуги, в том числе через средства массовой информации, включая

размещение информации на официальных сайтах в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (далее – сеть «Интернет»);

7) организацию профессионального обучения, профессионального образования и дополнительного профессионального образования работников поставщиков социальных услуг;

8) ведение учета и отчетности в сфере социального обслуживания в Республике Татарстан;

9) разработку и апробацию методик и технологий в сфере социального обслуживания;

10) формирование с участием общественных организаций общественного совета по проведению независимой оценки качества оказания услуг организациями социального обслуживания Республики Татарстан, утверждение положения о нем;

11) размещение на своем официальном сайте в сети «Интернет» и на официальном сайте для размещения информации о государственных и муниципальных учреждениях в сети «Интернет» информации о результатах независимой оценки качества оказания услуг организациями социального обслуживания Республики Татарстан;

12) обеспечение на своем официальном сайте в сети «Интернет» технической возможности выражения мнения получателями социальных услуг о качестве оказания услуг организациями социального обслуживания Республики Татарстан;

13) разработку и реализацию мероприятий по формированию и развитию рынка социальных услуг, в том числе по развитию негосударственных организаций социального обслуживания;

14) иные полномочия, предусмотренные законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан.

## Глава 3. **Организация социального обслуживания граждан в Республике Татарстан**

### Статья 6. **Номенклатура организаций социального обслуживания Республики Татарстан**

1. К организациям социального обслуживания Республики Татарстан, осуществляющим стационарное социальное обслуживание, относятся:

1) дом-интернат (пансионат) для престарелых и инвалидов;

2) специальный дом-интернат для престарелых и инвалидов;

3) психоневрологический интернат;

4) детский дом-интернат для умственно отсталых детей;

5) дом-интернат для детей с физическими недостатками;

6) социальный приют для детей и подростков;

7) социально-реабилитационный центр для несовершеннолетних;

8) центр реабилитации инвалидов;

9) центр социальной адаптации для лиц без определенного места жительства и занятий.

2. В состав организаций социального обслуживания Республики Татарстан, осуществляющих стационарное социальное обслуживание, могут быть включены отделения полустационарного социального обслуживания.

3. К организациям социального обслуживания Республики Татарстан, осуществляющим полустационарное социальное обслуживание, относятся:

1) комплексный центр социального обслуживания населения;

2) центр социальной помощи семье и детям;

3) реабилитационный центр для детей и подростков с ограниченными возможностями;

4) центр социальной реабилитации слепых и слабовидящих.

4. В состав организаций социального обслуживания Республики Татарстан, осуществляющих полустационарное социальное обслуживание, могут быть включены отделения стационарного социального обслуживания, отделения социального обслуживания на дому и отделения, предоставляющие срочные социальные услуги.

Статья 7. **Признание гражданина нуждающимся в социальном обслуживании**

1. В Республике Татарстан гражданин признается нуждающимся в социальном обслуживании при наличии следующих обстоятельств, которые ухудшают или могут ухудшить условия его жизнедеятельности:

1) обстоятельства, установленные Федеральным законом «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации»;

2) последствия чрезвычайных ситуаций, вооруженных межнациональных (межэтнических) конфликтов.

2. Признание гражданина нуждающимся в социальном обслуживании, определение его индивидуальной потребности в социальных услугах и составление индивидуальной программы предоставления социальных услуг осуществляются уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Статья 8. **Социальные услуги, предоставляемые в Республике Татарстан поставщиками социальных услуг**

1. К социально-бытовым услугам, предоставляемым в Республике Татарстан поставщиками социальных услуг, относятся:

1) в форме социального обслуживания на дому:

а) покупка за счет средств получателя социальных услуг и доставка продуктов питания, промышленных товаров первой необходимости, средств санитарии и гигиены, средств ухода, лекарственных средств и медицинских изделий, книг, газет, журналов, билетов на культурно-досуговые мероприятия;

б) помощь в приготовлении или приготовление пищи;

в) оплата за счет средств получателя социальных услуг жилищно-коммунальных услуг и услуг связи;

г) покупка за счет средств получателя социальных услуг топлива, топка печей, обеспечение водой (в жилых помещениях без центрального отопления и (или) водоснабжения);

д) сдача за счет средств получателя социальных услуг вещей в стирку, химчистку, ремонт, обратная их доставка;

2) в стационарной форме социального обслуживания:

а) предоставление площадей жилых помещений согласно нормативам, утвержденным Кабинетом Министров Республики Татарстан;

б) организация транспортной доставки в медицинские организации;

3) в полустационарной форме социального обслуживания – организация транспортной доставки детей-инвалидов, имеющих ограничение способности к передвижению 3-й степени, в реабилитационные центры для детей и подростков с ограниченными возможностями и обратно;

4) в полустационарной и стационарной формах социального обслуживания:

а) обеспечение питанием согласно нормам, утвержденным Кабинетом Министров Республики Татарстан;

б) предоставление площадей для оказания социальных услуг согласно нормативам, утвержденным Кабинетом Министров Республики Татарстан;

в) обеспечение мягким инвентарем и товарами санитарно-гигиенического назначения согласно нормативам, утвержденным Кабинетом Министров Республики Татарстан;

5) в форме социального обслуживания на дому, в стационарной форме социального обслуживания:

а) уборка жилых помещений;

б) предоставление гигиенических услуг лицам, не способным по состоянию здоровья самостоятельно выполнять их;

в) отправка за счет средств получателя социальных услуг почтовой корреспонденции;

г) помощь в приеме пищи (кормление).

2. К социально-медицинским услугам, предоставляемым в Республике Татарстан поставщиками социальных услуг, относятся:

1) во всех формах социального обслуживания:

а) выполнение процедур, связанных с наблюдением за состоянием здоровья получателей социальных услуг;

б) проведение по назначению врача медицинских процедур;

в) проведение оздоровительных мероприятий;

г) систематическое наблюдение за получателями социальных услуг в целях выявления отклонений в состоянии их здоровья;

д) консультирование по социально-медицинским вопросам;

2) в стационарной и полустационарной формах социального обслуживания:

а) проведение медицинского осмотра врачом;

б) проведение медицинских реабилитационных мероприятий;

в) проведение мероприятий, направленных на формирование здорового образа жизни;

г) проведение занятий по адаптивной физической культуре.

3. К социально-психологическим услугам, предоставляемым в Республике Татарстан поставщиками социальных услуг, относятся:

1) в стационарной и полустационарной формах социального обслуживания:

а) социально-психологическое консультирование, в том числе по вопросам внутрисемейных отношений;

б) психологическая помощь и поддержка, в том числе гражданам, осуществляющим уход на дому за нуждающимися в постоянном постороннем уходе инвалидами (детьми-инвалидами);

2) в полустационарной форме социального обслуживания – социально-психологический патронаж.

4. К социально-педагогическим услугам, предоставляемым в Республике Татарстан поставщиками социальных услуг, относятся:

1) в стационарной и полустационарной формах социального обслуживания:

а) обучение родственников практическим навыкам общего ухода за нуждающимися в постоянном постороннем уходе инвалидами (детьми-инвалидами);

б) социально-педагогическая коррекция, включая диагностику и консультирование;

в) формирование позитивных интересов;

г) организация досуга;

2) в форме социального обслуживания на дому, полустационарной форме социального обслуживания – организация помощи родителям или законным представителям детей-инвалидов, воспитываемых дома, в обучении таких детей навыкам самообслуживания, общения и контроля, направленным на развитие личности.

5. К социально-трудовым услугам, предоставляемым в Республике Татарстан в стационарной и полустационарной формах социального обслуживания поставщиками социальных услуг, относятся:

1) проведение мероприятий по использованию трудовых возможностей и обучению доступным профессиональным навыкам;

2) организация помощи в получении образования и (или) профессии инвалидами (детьми-инвалидами) в соответствии с их способностями;

3) оказание помощи в трудоустройстве.

6. К социально-правовым услугам, предоставляемым в Республике Татарстан во всех формах социального обслуживания поставщиками социальных услуг, относятся:

1) оказание помощи в оформлении и восстановлении документов получателей социальных услуг;

2) оказание помощи в получении юридических услуг.

7. К услугам в целях повышения коммуникативного потенциала получателей социальных услуг, имеющих ограничения жизнедеятельности, в том числе детей-инвалидов, предоставляемым в Республике Татарстан в стационарной и полустационарной формах социального обслуживания поставщиками социальных услуг, относятся:

1) обучение инвалидов (детей-инвалидов) пользованию средствами ухода и техническими средствами реабилитации;

2) проведение социально-реабилитационных мероприятий в сфере социального обслуживания;

3) обучение навыкам самообслуживания, поведения в быту и общественных местах.

8. К срочным социальным услугам, предоставляемым в Республике Татарстан поставщиками социальных услуг, относятся:

1) обеспечение бесплатным горячим питанием или наборами продуктов;

2) обеспечение одеждой, обувью и другими предметами первой необходимости;

3) содействие в получении временного жилого помещения;

4) содействие в получении юридической помощи в целях защиты прав и законных интересов получателей социальных услуг;

5) содействие в получении экстренной психологической помощи.

### Статья 9. **Социальное сопровождение**

При необходимости гражданам оказывается содействие в предоставлении медицинской, психологической, педагогической, юридической, социальной помощи, не относящейся к социальным услугам (социальное сопровождение), путем привлечения организаций, предоставляющих такую помощь, в соответствии с регламентом межведомственного взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан в связи с реализацией полномочий Республики Татарстан в сфере социального обслуживания. Мероприятия по социальному сопровождению отражаются в индивидуальной программе предоставления социальных услуг.

## Глава 4. **Финансирование социального обслуживания и условия оплаты социальных услуг**

### Статья 10. **Финансовое обеспечение социального обслуживания**

1. Источниками финансового обеспечения социального обслуживания в Республике Татарстан являются:

1) средства бюджета Республики Татарстан;

2) благотворительные взносы и пожертвования;

3) средства получателей социальных услуг при предоставлении социальных услуг за плату или частичную плату;

4) доходы от приносящей доход деятельности, осуществляемой организациями социального обслуживания Республики Татарстан, а также иные не запрещенные законодательством источники.

2. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания вправе привлекать иные источники финансирования социального обслуживания, в том числе для реализации совместных проектов (программ), принимаемых в сфере социального обслуживания на республиканском и муниципальном уровнях.

3. Размер и порядок выплаты компенсации за предоставление социальных услуг, предусмотренных индивидуальной программой предоставления социальных услуг, поставщикам социальных услуг, которые включены в реестр поставщиков социальных услуг в Республике Татарстан, но не участвуют в выполнении государственного задания (заказа), устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

4. Порядок расходования средств, образовавшихся в результате взимания платы за предоставление социальных услуг, для организаций социального обслуживания Республики Татарстан устанавливается уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в сфере социального обслуживания.

5. Формирование государственного заказа на оказание социальных услуг в Республике Татарстан негосударственными организациями и индивидуальными предпринимателями в Республике Татарстан осуществляется в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Статья 11. **Предоставление социальных услуг бесплатно**

1. В Республике Татарстан социальные услуги в форме социального обслуживания на дому, полустационарной и стационарной формах социального обслуживания предоставляются бесплатно категориям граждан, указанным в части 1 статьи 31 Федерального закона «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации».

2. Социальные услуги в форме социального обслуживания на дому, в полустационарной форме социального обслуживания, в стационарной форме социального обслуживания в центрах реабилитации инвалидов и социально-реабилитационных отделениях комплексных центров социального обслуживания населения предоставляются бесплатно, если на дату обращения среднедушевой доход получателя социальных услуг, рассчитанный в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации, ниже предельной величины или равен предельной величине среднедушевого дохода для предоставления социальных услуг бесплатно, установленной частью 4 настоящей статьи.

3. Нормативными правовыми актами Кабинета Министров Республики Татарстан могут быть предусмотрены иные категории граждан, которым социальные услуги предоставляются бесплатно.

4. Размер предельной величины среднедушевого дохода для предоставления социальных услуг в Республике Татарстан бесплатно соответствует полуторной величине прожиточного минимума, установленного в Республике Татарстан для соответствующих социально-демографических групп населения по итогам второго квартала года, предшествующего году предоставления социальной услуги.

### Статья 12. **Размер ежемесячной платы за предоставление социальных услуг в стационарной форме социального обслуживания**

Размер ежемесячной платы за предоставление социальных услуг в стационарной форме социального обслуживания рассчитывается на основе тарифов на социальные услуги, но не может превышать 75 процентов среднедушевого дохода получателя социальных услуг, рассчитанного в соответствии с частью 4 статьи 31 Федерального закона «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации».

## Глава 5. **Заключительные и переходные положения**

### Статья 13. **Переходные положения**

В рамках длящихся правоотношений для получателей социальных услуг, у которых право на получение социальных услуг возникло в соответствии с действовавшим до дня вступления в силу настоящего Закона порядком предоставления социальных услуг в Республике Татарстан, вновь устанавливаемые размеры платы за предоставление социальных услуг поставщиками социальных услуг в Республике Татарстан и условия ее предоставления в соответствии с настоящим Законом не могут быть выше размеров платы за предоставление этим лицам соответствующих социальных услуг, установленных по состоянию на 31 декабря 2014 года, а условия предоставления соответствующих социальных услуг не могут быть ухудшены по сравнению с условиями, установленными по состоянию на 31 декабря 2014 года.

### Статья 14. **Ответственность за нарушение настоящего Закона**

Ответственность за нарушение настоящего Закона наступает в порядке и на основаниях, которые предусмотрены законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан.

### Статья 15. **Обжалование действий (бездействия) организаций социального обслуживания Республики Татарстан**

Действия (бездействие) организаций социального обслуживания Республики Татарстан могут быть обжалованы получателем социальных услуг,

его опекуном, попечителем либо другим законным представителем в соответствующие органы государственной власти либо в суд.

Статья 16. **О признании утратившим силу законодательного акта Республики Татарстан**

Признать утратившим силу Закон Республики Татарстан от 13 ноября 2006 года № 69-ЗРТ «О социальном обслуживании населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 11 (I часть).

Статья 17. **Вступление в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2015 года.
2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои нормативные правовые акты в соответствие с настоящим Законом, а также принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
18 декабря 2014 года
№ 126-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

## 1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

### 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү өлкәсе) аерым мәсьәләләрне җайга сала.

### 2 статья. **Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләр “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль закон), аның нигезендә кабул ителә торган башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән җайга салына.
2. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

## 2 бүлек. **Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

### 3 статья. **Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне законнар чыгарып җайга салу;

2) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль законда һәм әлеге Законда каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органын (алга таба – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы) билгеләү;

2) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт программаларын раслау, финанс ягыннан тәэмин итү;

3) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә программаларны, шул исәптән инвестиция программаларын, гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

4) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының ведомствоара хезмәттәшлек регламентын раслау;

5) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау;

6) Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының (алга таба – Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) штат саны нормативларын, күрсәтелгән оешмалар тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырганда йомшак инвентарь һәм торак урыннар мәйданы белән тәэмин итү нормативларын раслау;

7) Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында туклану нормаларын раслау;

8) социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау;

9) Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне финанслауның бер кешегә исәпләнгән нормативлары нигезендә социаль хезмәт күрсәтүләргә тарифларны раслау тәртибен билгеләү;

10) социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырган өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау;

11) социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырганда һәм социаль карамакта торганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен раслау;

12) социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләрнең реестрын һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның регистрын булдыру һәм алып бару тәртибен раслау;

13) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга, хәйриячеләргә һәм үз теләге белән эшләүчеләргә ярдәм итүне оештыру;

14) Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә социаль ярдәм һәм кызыксындыру чараларын билгеләү;

15) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт идарәсен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүне;

2) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика дәүләт контролен (күзәтчелеген);

3) Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен;

4) Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләрнең, иҗтимагый оешмаларның һәм башка оешмаларның эшчәнлеген координацияләүне;

5) социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләрнең реестрын һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның регистрын булдыруны һәм алып баруны;

6) социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр, алар тарафыннан гамәлгә ашырылган социаль хезмәт күрсәтүләр, социаль хезмәт күрсәтүләр төрләре, аларны күрсәтү вакытлары, тәртибе һәм шартлары турында, әлеге хезмәт күрсәтүләргә тарифлар турында мәгълүматтан түләүсез файдалануны, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – "Интернет" челтәре) рәсми сайтларда мәгълүмат урнаштыруны кертеп, тәэмин итүне;

7) социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүче хезмәткәрләрнең һөнәри укуын, һөнәри белем алуын һәм өстәмә һөнәри белем алуын оештыруны;

8) Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә исәпкә алуны һәм хисаплылык алып баруны;

9) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә методикалар һәм технологияләр эшләүне һәм апробацияләүне;

10) Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый оешмалар катнашында иҗтимагый совет төзүне, аның турында нигезләмә раслауны;

11) "Интернет" челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм "Интернет" челтәрендәге дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүматны урнаштыру өчен рәсми сайтта Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыруны;

12) "Интернет" челтәрендәге үзенең рәсми сайтында Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты турында социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның фикерен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итүне;

13) социаль хезмәт күрсәтүләр базарын булдыру һәм үстерү, шул исәптән дәүләтнеке булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын үстерү чараларын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны;

14) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне.

## 3 бүлек. **Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтүне оештыру**

### 6 статья. **Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү оешмалары номенклатурасы**

1. Стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына түбәндәгеләр керә:

1) картлар һәм инвалидлар өчен интернат йорт (пансионат);

2) картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йорт;

3) психоневрологик интернат;

4) акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йорты;

5) физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йорт;

6) балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют;

7) балигъ булмаганнар өчен социаль реабилитация үзәге;

8) инвалидларны реабилитацияләү үзәге;

9) билгеле яшәү урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәге.

2. Стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары составына ярымстационар социаль хезмәт күрсәтү бүлекләре кертелергә мөмкин.

3. Ярымстационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына түбәндәгеләр керә:

1) халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәге;

2) гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге;

3) мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәге;

4) сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль реабилитацияләү үзәге.

4. Ярымстационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары составына стационар социаль хезмәт күрсәтү бүлекләре, өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү бүлекләре һәм ашыгыч социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыручы бүлекләр кертелергә мөмкин.

7 статья. **Гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗлыгын тану**

1. Татарстан Республикасында граждан аның яшәеш шартларын начарайта торган яисә начарайтырга мөмкин булган түбәндәге хәлләр булганда, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип таныла:

1) “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль законда билгеләнгән хәлләр;

2) гадәттән тыш хәлләр, кораллы милләтара (этникара) конфликтлар нәтиҗәләре.

2. Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану, аның социаль хезмәт күрсәтүләргә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү һәм социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыруның индивидуаль программасын төзү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8 статья. **Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль хезмәт күрсәтүләр**

1. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган социаль-көнкүреш хезмәт күрсәтүләренә түбәндәгеләр керә:

1) өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә:

а) туклану продуктлары, көндәлек сәнәгать товарлары, санитария һәм гигиена чаралары, үз-үзеңне карап тоту чаралары, дарулар һәм медицина әйберләре, китаплар, газеталар, журналлар, мәдәни-ял итү чараларына билетлар социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы акчалары исәбеннән сатып алу һәм китереп бирү;

б) ризык әзерләргә ярдәм итү яисә әзерләү;

в) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы акчалары исәбеннән торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр һәм элемтә хезмәт күрсәтүләре өчен түләү;

г) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы акчалары исәбеннән ягулык сатып алу, мичкә ягу, су китерү (үзәктән җылытылмый һәм (яисә) су белән тәэмин ителми торган торак урыннарда);

д) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы акчалары исәбеннән әйберләрне юарга, химчисткага, ремонтка бирү, аларны кайтарып бирү;

2) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә торак урыннар мәйданнары бирү;

б) медицина оешмаларына транспорт белән китерүне оештыру;

3) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә – йөрү сәләте чикле булуның 3 дәрәҗәсендәге инвалид балаларны мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәкләренә транспортта китерүне һәм кире алып кайтуны оештыру;

4) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар һәм стационар рәвешләрендә:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормалар нигезендә туклануны тәэмин итү;

б) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру өчен мәйданнар бирү;

в) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нормативлар нигезендә йомшак инвентарь һәм санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итү;

5) өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә:

а) торак урыннарын җыештыру;

б) сәламәтлеге торышы буенча гигиена хезмәтләрен үзе башкара алмаган затларга шул хезмәтләрне күрсәтү;

в) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы акчалары исәбеннән почта корреспонденциясен җибәрү;

г) ашарга булышу (ашату).

2. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган социаль-медицина хезмәт күрсәтүләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль хезмәт күрсәтүнең бөтен рәвешләрендә:

а) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның сәламәтлеге торышын күзәтүгә бәйле процедуралар башкару;

б) табиб билгеләве буенча медицина процедуралары үткәрү;

в) сәламәтләндерү чаралары үткәрү;

г) сәламәтлеге торышында тайпылышларны ачыклау максатларында социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны системалы күзәтү;

д) социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультация бирү;

2) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешләрендә:

а) табиб тарафыннан медицина тикшерүе үткәрү;

б) медицина реабилитацияләве чараларын үткәрү;

в) сәламәт яшәү рәвешен булдыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү;

г) адаптив физик культура буенча дәресләр үткәрү.

3. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган социаль-психологик хезмәт күрсәтүләргә түбәндәгеләр керә:

1) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешләрендә:

а) социаль-психологик консультация бирү, шул исәптән гаиләдәге мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча;

б) психологик ярдәм, шул исәптән даими нигездә кеше тәрбиясенә мохтаҗ булган инвалидларны (инвалид балаларны) өйдә караучы гражданнарга;

2) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә – социаль-психологик патронаж.

4. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган социаль-педагогик хезмәт күрсәтүләргә түбәндәгеләр керә:

1) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешләрендә:

а) даими нигездә кеше тәрбиясенә мохтаҗ булган инвалидларны (инвалид балаларны) гомуми карап торуның гамәли күнекмәләренә аларның туганнарын өйрәтү;

б) социаль-педагогик коррекция, диагностиканы һәм консультация бирүне дә кертеп;

в) уңай кызыксыну булдыру;

г) ял итүне оештыру;

2) өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә – өйдә тәрбияләнүче инвалид балаларның ата-аналарына яисә законлы вәкилләренә мондый балаларны шәхес буларак үстерүгә юнәлдерелгән үз-үзләрен карау сәләте, аралашу һәм үзләрен контрольдә тоту күнекмәләренә өйрәтүдә ярдәм итүне оештыру.

5. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешләрендә күрсәтелә торган социаль-хезмәт хезмәт күрсәтүләренә түбәндәгеләр керә:

1) хезмәт мөмкинлекләреннән файдалану һәм мөмкин булган һөнәри күнекмәләргә өйрәтү чаралары үткәрү;

2) сәләтләренә карап, инвалидларның (инвалид балаларның) белем һәм (яисә) һөнәр алуына ярдәм итүне оештыру;

3) эшкә урнашуда ярдәм итү.

6. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең барлык рәвешләрендә күрсәтелә торган социаль-хокукый хезмәт күрсәтүләргә түбәндәгеләр керә:

1) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның документларын рәсмиләштерүдә һәм торгызуда ярдәм итү;

2) юридик хезмәт күрсәтүләрдән файдалануда ярдәм итү.

7. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләрдән яшәү мөмкинлекләре чикле булган файдаланучыларның, шул исәптән инвалид балаларның, коммуникатив потенциалын арттыру максатларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешләрендә күрсәтелә торган хезмәт күрсәтүләргә түбәндәгеләр керә:

1) инвалидларны (инвалид балаларны) үз-үзләрен карап тору чараларыннан һәм реабилитацияләүнең техник чараларыннан файдалануга өйрәтү;

2) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль реабилитация чаралары үткәрү;

3) үз-үзен карау, көнкүрештә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзен тоту күнекмәләренә өйрәтү.

8. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган ашыгыч социаль хезмәт күрсәтүләргә түбәндәгеләр керә:

1) түләүсез кайнар ризык яисә продуктлар җыелмасы белән тәэмин итү;

2) кием, аяк киеме һәм башка көндәлек кирәк-яраклары белән тәэмин итү;

3) вакытлы торак урыны алырга ярдәм итү;

4) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында юридик ярдәм алуда булышлык күрсәтү;

5) ашыгыч психологик ярдәм алуда булышлык күрсәтү.

9 статья. **Социаль карамакта тоту**

Гражданнарга, кирәк булганда, социаль хезмәт күрсәтүләргә карамаган медицина, психологик, педагогик, юридик, социаль ярдәм алуда (социаль карамакта тотуда) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара хезмәттәшлек регламенты нигезендә мондый ярдәм күрсәтүче оешмаларны җәлеп итү юлы белән булышлык күрсәтелә. Социаль карамакта тоту чаралары социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасында күрсәтелә.

4 бүлек. **Социаль хезмәт күрсәтүне финанслау һәм социаль хезмәт күрсәтүләргә түләү шартлары**

10 статья. **Социаль хезмәт күрсәтүне финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүне финанс ягыннан тәэмин итү чыганакларына түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

2) хәйрия кертемнәре һәм иганәләр;

3) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның социаль хезмәт күрсәтүләр өчен түли торган яисә өлешчә түли торган акчалары;

4) Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының керем китерә торган эшчәнлегеннән керемнәре, шулай ук законнар белән тыелмаган башка чыганаклар.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы социаль хезмәт күрсәтүне финанслауның башка чыганакларын, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә кабул ителә торган уртак проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру өчен, җәлеп итәргә хокуклы.

3. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләрнең реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләргә социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасында каралган социаль хезмәт күрсәтүләрне

гамәлгә ашырган өчен компенсация күләме һәм аны түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырган өчен түләү алу нәтиҗәсендә барлыкка килгән акчаларны Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары өчен тоту тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасында дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыруга дәүләт заказын булдыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

11 статья. **Социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашыру**

1. Татарстан Республикасында өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, хезмәт күрсәтүнең ярымстационар һәм стационар рәвешләрендә социаль хезмәт күрсәтүләр “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль законның 31 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарга түләүсез гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр мөрәҗәгать итү датасына социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә бер кешегә уртача исәпләнгән кереме социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашырган өчен әлеге статьяның 4 өлешендә билгеләнгән бер кешегә уртача исәпләнгән керемнең чик күләменнән аз яисә чик күләменә тигез булса, өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, инвалидларны реабилитацияләү үзәкләрендә һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-реабилитация бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләр түләүсез гамәлгә ашырыла,

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашыру башка категориядәге гражданнарга каралырга мөмкин.

4. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашыру өчен бер кешегә уртача исәпләнгән керемнең чик күләме социаль хезмәт күрсәтү елыннан алда килгән елның икенче кварталы йомгаклары буенча халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының бер ярым күләменә туры килә.

12 статья. **Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырган өчен айлык түләү күләме**

Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырган өчен айлык түләү күләме социаль хезмәт күрсәтүләргә тарифлар нигезендә исәпләнә, әмма ул “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль законның

31 статьясындагы 4 өлеше нигезендә исәпләнгән социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының бер кешегә уртача исәпләнгән кеременең 75 процентыннан арта алмый.

## 5 бүлек. **Йомгаклау һәм күчмә нигезләмәләр**

### 13 статья. **Күчмә нигезләмәләр**

Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану хокуклары әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә барлыкка килгән социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар өчен дәвам ителә торган хокукый мөнәсәбәтләр кысаларында Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырган өчен түләүнең яңадан билгеләнә торган күләмнәре һәм аны бирү тәртибе әлеге Закон нигезендә шушы затларга тиешле социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырган өчен 2014 елның 31 декабренә билгеләнгән түләү күләмнәреннән артыграк була алмый, ә тиешле социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру шартлары 2014 елның 31 декабренә билгеләнгән шартлар белән чагыштырганда начаррак була алмый.

### 14 статья. **Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык**

Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә һәм нигезләрдә барлыкка килә.

### 15 статья. **Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү**

Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары гамәлләренә (гамәл кылмавына) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы, аның опекуны, попечителе йә башка законлы вәкиле тарафыннан дәүләт хакимиятенең тиешле органнарына йә судка шикаять бирелергә мөмкин.

### 16 статья. **Татарстан Республикасы закон актының үз көчен югалтуын тану турында**

“Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү турында” 2006 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 11 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

### 17 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 18 декабре
№ 126-ТРЗ